ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11. 03. 2019 г.Мензелинск №230

«Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының «Юбилейный» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе исемен үзгәртү һәм учреждение Уставын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019елның 21 декабрендәге №28 «Өстәмә белем бирү дәүләт учреждениеләренең исемен үзгәртү турында» карары нигезендә,Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы башкарма комитеты,

КАРАР ЧЫГАРА:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының «Юбилейный» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе исемен Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының «Юбилейный» спорт мәктәбе (алга таба - Учреждение) муниципаль бюджет учреждениесенә үзгәртергә.
2. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының «Юбилейный» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе Уставын расларга.
3. Учреждение директоры Бәдриев Рәмзил Рафаиловичның салым органында билгеләнгән закон тәртибендә яңадан теркәлү буенча вәкаләтләрен йөкләү.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» МКУ җитәкчесе Ф.Г.Хизбуллинга йөкләргә.

Җитәкче К. Р. Нәҗмиев